# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2021 елның 19 ноябре № 49

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында, аның предметы булып, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу һәм Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Өтәшкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу булган вәкаләтләрен тапшырырга.

2.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча, аның предметы булып, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу булган вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзергә тәкъдим итәргә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен тормышка ашыруны Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авыл җирлеге бюджетыннан ел саен Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкаралар.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, җәмәгать тәртибе, иҗтимагый оешмалар белән эшләү, регламент һәм депутат этикасы буенча комиссиягә йөкләргә.

**Өтәшкә авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **А.А. Клопов**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1620001214
ОГРН 1021606753486